**Казан шәһәре Башкарма комитетының**
**2025 елның 12 сентябрендәге 2866 номерлы карары**

**Казан шәһәре Башкарма комитетының**
**2018 елның 31 августындагы 4747 номерлы**
**«Казан шәһәренең муниципаль яшьләр сәясәте оешмалары хезмәткәрләренең хезмәтенә түләү шартлары турында»гы карарына үзгәрешләр кертү хакында**

Казан шәһәренең «Девиант тәртипле балалар һәм яшүсмерләр өчен “Дуслык” социаль-тернәкләндерү үзәге» муниципаль бюджет яшьләр сәясәте учреждениесе эшчәнлегенең нәтиҗәлелеген арттыру максатыннан **карар бирәм:**

1. Казан шәһәре Башкарма комитетының 2018 елның 31 августындагы 4747 номерлы «Казан шәһәрендәге яшьләр сәясәте муниципаль оешмалары хезмәткәрләренең хезмәтенә түләү шартлары турында»гы карарына (аңа Казан шәһәре Башкарма комитетының 2019 елның 24 июнендәге 2256 номерлы, 2024 елның 15 августындагы 3370 номерлы, 2025 елның 14 маендагы 1455 номерлы, 2025 елның 20 июнендәге 1864 номерлы карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) 2 номерлы кушымтасының IV бүлегендә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 4.2 пунктчаны түбәндәге редакциядә бирергә:

«4.2. Стимуллаштыру характерындагы түләүләр түбәндәгеләрне үз эченә ала:

- мактаулы исемнәр булган өчен түләүләр;
- вазифа буенча эш стажы өчен түләүләр;
- премия һәм башка кызыксындыру түләүләре;
- хезмәт киеренкелеге өчен түләүләр»;

1.2. түбәндәге эчтәлекле 4.6 пунктчасын өстәргә:

«4.6. Түләүләр Казан шәһәренең «Девиант тәртипле балалар һәм яшүсмерләр өчен “Дуслык” социаль-тернәкләндерү үзәге» муниципаль бюджет яшьләр сәясәте учреждениесенең «пешекче» һәм «ярдәмче хезмәткәр»

вазифалары буенча гомумтармак эшче һөнәрләренең һөнәри квалификация төркемнәренә керә торган хезмәткәрләргә 40 һәм 25 процент күләмендә (шул ук тәртиптә) бирелә һәм түбәндәге формула буенча исәпләнә:

$$B_{sd} = O_d \times \frac{D_{sd}}{100\%}$$, биредә

Od – «пешекче» һәм «ярдәмче хезмәткәр» вазифалары буенча гомумтармак һөнәрләренең һөнәри квалификация төркемнәре хезмәткәрләренең вазифаи оклады;

$D_{sd}$ – хезмәт киеренкелеге өчен өстәмә түләү күләме».

2. Әлеге карарның йогынтысы 2025 елның 1 сентябреннән барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла дип билгеләргә.

3. Әлеге карарны «Муниципаль хокукый актлар һәм башка рәсми мәгълүмат» челтәр басмасында (www.docskzn.ru) бастырырга, Казан шәһәре җирле үзидарә органнарының рәсми порталында (www.kzn.ru), Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (www.pravo.tatarstan.ru) урнаштырырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Казан шәһәре Башкарма комитеты Җитәкчесе урынбасары Г.Р.Сәгыйтовага йөкләргә.

**Җитәкче вазифаларын башкаручы –**
**беренче урынбасар** **А.Р.Нигъмәтҗанов**